**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№М 581**
**15.12.2023**

Шәһәр Хакименең 2016 елның 24 мартындагы М 98 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре реестрларын алып бару турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Мниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең 2016 елның 24 мартындагы М 98 номерлы Карары (Шәһәр Хакименең 2021 елның 12 июлендәге М 272 номерлы Карары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре реестрларын алып бару турында нигезләмәнең 9 пунктына, икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Муниципаль хезмәткәрләр реестрларының формасы Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (алга таба – Департамент) тарафыннан раслана һәм Мәгълүмат системасында урнаштырыла.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка, Контроль-хисап палатасы Рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев